КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июль г.Казань № 548

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән расланган Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 май, 289 нчы; 2018 ел, 7 февраль, 64 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «15. | Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә «Татарстан гасыры» мәгариф проектын тормышка ашыру | 2017 – 2018 еллар | Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, «Татармультфильм» балалар анимация студиясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча)»; |

52 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «52. | «Татар музыкасы гасыры – «Татарстан аһәңнәре» мульти-медиа интернет-порталын булдыру һәм аңа мәгълүмати булышлык күрсәтү | 2017 – 2019 еллар | Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге (килешү буенча)»; |

60 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «60. | «Россия төбәкләренең халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләре: Татарстан Респуб-ликасы тәҗрибәсе» күмәк монографиясен эшләү һәм бастырып чыгару | 2017 ел | Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән мини-стрлыгы, Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгыш институты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты (килешү буенча)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин